# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында
2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

18.12.2024 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылы торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Үзара салымны 2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, түбәндәге категорияләрдән тыш, балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә кертергә:

а) уку йортлары студентлары;

б) Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итүче затлар һәм контракт һәм мобилизация буенча хезмәткәрләр;

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә: Карамышиха авылы торак пункты чикләрендә Үзәк урамындагы гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга җибәрергә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова